РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«25» декабрь 2018 ел г. Альметьевск № 2256

«Әлмәт муниципаль районында
2019 елга юл хәрәкәте иминлеген арттыру»
муниципаль программасын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 ел 6 октябрь №131-ФЗ Федераль законга, «Юл хәрәкәте иминлеге турында» 1995 ел 10 декабрь №196-ФЗ Федераль законга,Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2013-2020 елларда юл хәрәкәте иминлеген арттыру федераль максатчан программасы турында» 2013 ел 3 октябрь № 864 карарлары, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү чаралары турында» 2014 ел 6 декабрь ПУ-1115 номерлы Указы, Әлмәт муниципаль районы Уставына нигезләнеп

БАШКАРМА КОМИТЕТЫ КАРАР БИРӘ:

1. «2019 елга Әлмәт муниципаль районында юл хәрәкәте иминлеген арттыру» муниципаль программасын расларга (1 нче кушымта).

2. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының финанс-бюджет палатасына (Шәйдуллина З.Р.) чираттагы финанс елына җирле бюджет формалаштырганда программаны гамәлгә ашыруга финанс чаралары бүлеп бирүне алдан карарга тәкъдим итәргә.

3. Район башкарма комитетының хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны " Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга (PRAVO.TATARSTAN.RU).

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район башкарма комитеты җитәкчесенең төзелеш буенча урынбасары А.А. Мөхәммәтҗановка йөкләргә.

Район башкарма комитеты җитәкчесе М.Н.Гирфанов

ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ

Зак. № 3063

1 нче кушымта
Әлмәт муниципаль районы
башкарма комитетының
«25» декабрь 20 18 ел № 2256
карары белән расланган

"2019 елга Әлмәт муниципаль районында
юл хәрәкәте иминлеген арттыру»
МУНИЦИПАЛЬ ПРОГРАММАСЫ

Әлмәт, 2018

“2019 елга Әлмәт муниципаль районында юл хәрәкәте иминлеген арттыру”муниципаль программасы паспорты

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | “2019 елга Әлмәт муниципаль районында юл хәрәкәте иминлеген арттыру” муниципаль программасы |
| Программа эшләүнең нигезе | "2013-2020 елларда юл хәрәкәте иминлеген арттыру” федераль максатчан программасы турында 2013 елның 3 октябрендәге 864 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары»; Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү чаралары турында" 2014 елның 6 декабрендәге ПУ-1115 номерлы Указы; "2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы тору” дәүләт программасын раслау турында 2013 елның 16 октябрендәге 764 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары; «Татарстан Республикасы дәүләт программаларын эшләү, гамәлгә ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен һәм Татарстан Республикасы дәүләт программалары исемлеген раслау турында" 2012 елның 31 декабрендәге 1199 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары; Юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү буенча Татарстан Республикасы Хөкүмәт комиссиясенең 2017 елның 26 январындагы 1 номерлы карары белән расланган “Юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү буенча Татарстан Республикасы Хөкүмәт комиссиясе” нең 2018 елның 28 сентябрендәге 4 номерлы карары, Әлмәт муниципаль районы Уставы белән расланган Юл хәрәкәте иминлеген арттыру буенча Татарстан Республикасы муниципаль программаларын эшләү һәм гамәлгә ашыру регламенты |
| Программаның заказчысы | Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы башкарма комитеты, Россия Эчке эшләр министрлыгының Әлмәт районы буенча Юл хәрәкәте куркынычсызлыгы дәүләт инспекциясе бүлеге (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Программаны эшләүче | Район башкарма комитетының төзелеш, элемтә, транспорт һәм юл хуҗалыгы идарәсе |
| Программа кураторлары | Әлмәт муниципаль районы башкарма комитетының төзелеш, элемтә, транспорт һәм юл хуҗалыгы идарәсе, Россия Эчке эшләр министрлыгының Әлмәт районы буенча Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясе бүлеге (килешү буенча), «Юл хәрәкәте иминлеге» дәүләт бюджет учреждениесенең Әлмәт шәһәрендәге территориаль бүлеге (килешү буенча). |
| Программаның максатлары һәм бурычлары | Программаның максаты-гражданнарның гомерен, сәламәтлеген һәм аларның мөлкәтен саклауны тәэмин итү, Әлмәт муниципаль районы юлларында имин хәрәкәт итү шартларына аларның законлы хокукларын арттыру. Максатка ирешү шарты булып түбәндәге бурычларны хәл итү тора:<br>- юл хәрәкәтендә катнашучыларның куркыныч янау очрагында тәртибен кисәтү системасын камилләштерү;<br>- балаларда юлларда куркынычсызлык күнекмәләре формалаштыру;<br>- транспорт чаралары һәм җәяүлеләр хәрәкәтен оештыру системасын камилләштерү, юл шартларын яхшырту;<br>- юл-транспорт һәлакәтләрендә зыян күрүчеләргә ярдәм күрсәтү системасын үстерү;<br>- юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү өлкәсендә эшчәнлекне норматив-хокукый, оештыру һәм методик яктан тәэмин итүне камилләштерү |
| Программаның максатчан индикаторлары һәм күрсәткечләре | - юл-транспорт һәлакәтләрендә һәлак булучылар саны;<br>- юл-транспорт һәлакәтләрендә һәлак булган балалар саны;<br>- социаль куркыныч (юл-транспорт һәлакәтләрендә һәлак булучылар саны 100 мең кешегә);<br>- транспорт куркынычы (юл-транспорт һәлакәтләрендә һәлак булучылар саны 10 мең транспорт чарасына) |

| | |
|---|---|
| Программаны гамәлгә ашыру сроклары | Программа 2019 елга исәпләнгән |
| Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары | Программа буенча финанслауның гомуми күләме 22,388 млн сум тәшкил итә, шул исәптән:<br>- Федераль бюджет акчасыннан 5,459 млн сум;<br>- Татарстан Республикасы бюджеты акчаларыннан 0,470 млн сум;<br>- Муниципаль берәмлек бюджеты акчасыннан 4,309 млн сум;<br>- Бюджеттан тыш чыганаклардан 12,150 млн сум. |
| Программаның көтелгән нәтиҗәләре | 2012 ел белән чагыштырганда программаның мөһим индикаторларының уңай күрсәткечләренә ирешү:<br>- Транспорт һәм социаль хәвеф-хәтәр, юл-транспорт һәлакәтләренең авырлыгын киметү;<br>- юл-транспорт һәлакәтләре саны кимү;<br>- балалар катнашында юл-транспорт һәлакәтләре санын киметү.<br><br>Программаны тормышка ашыруның социаль-икътисади нәтиҗәсе 64,994 млн сум тәшкил итәчәк.<br>Программаны тормышка ашыруның бюджет нәтиҗәсе 48,154 млн. сум тәшкил итәчәк.<br><br>Искәрмә:<br>Программаны финанслау күләме муниципаль бюджет акчалары хисабына фаразланган характерда һәм реаль мөмкинлекләрдән чыгып ачыкланырга тиеш |
| Программаның үтәлешен контрольдә тоту органы системасы | Программа чараларының үтәлешен Әлмәт муниципаль районында юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү буенча комиссия контрольдә тота |

# 1. ПРОБЛЕМАНЫҢ АСЫЛЫ

Әлмәт муниципаль районы халкының яшәешенә төп факторларның тәэсирен анализлау юл-транспорт һәлакәтләре нәтиҗәсендә күп кешенең һәлак булуын һәм имгәнүен күрсәтә.

Соңгы дистә еллар дәвамында авариялелек проблемасы Әлмәт муниципаль районы территориясендә теркәлгән автомобиль транспорты санының шактый артуына бәйле рәвештә аеруча кискен куелды.

Транспорт чаралары саны еллар буенча

Табл. № 1

| №№ | Транспорт чарасы тибы | Үлчәү берәмлеге | 2012 ел | 2013 ел | 2014 ел | 2015 ел | 2016 ел |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
| 1 | Җиңел | шт. | 54846 | 56159 | 59013 | 62303 | 65 000 |
| 2 | Йөк | шт. | 5820 | 4609 | 9455 | 9708 | 9738 |
| 3 | Автобуслар | шт. | 1963 | 903 | 2471 | 2403 | 2312 |
| 4 | Мото-транспорт | шт. | 516 | 314 | 369 | 409 | 489 |
| 5 | Прицеплар | шт. | 1724 | 1294 | 2072 | 2487 | 3470 |
| | Барлыгы: | шт. | 64869 | 63279 | 73 380 | 77310 | 81 009 |

Әлмәт муниципаль районының автомобильләштерү дәрәҗәсе 1 мең кешегә 394 берәмлек транспорт чарасы тәшкил итә.

2012 елдан башлап 2017 елга кадәр Әлмәт муниципаль районы территориясендә ЮХИДИ бүлеге мәгълүматлары буенча 1459 юл-транспорт һәлакәте теркәлгән, аларда 200 кеше үлгән һәм 2093 кеше тән җәрәхәтләре алган.

2018 елның 9 аенда 105 юл-транспорт һәлакәте булган, аларда 18 кеше үлгән һәм 138 кеше тән җәрәхәтләре алган.

2017 елның шул ук чорында 124 юл-транспорт һәлакәте булган, аларда 18 кеше үлгән һәм 142 кеше тән җәрәхәтләре алган.

Хәзерге заман юл-транспорт травматизмы үзенчәлекләрен анализлау юл-транспорт һәлакәтләренең саны акрынлап арта баруын, нәтиҗәдә, зыян күрүчеләр махсус дәрәҗәдәге җәрәхәтләр алуын күрсәтә.

Җәяүлеләр төркеме-юл хәрәкәтендә катнашучыларның иң күбесе.

2012, 2013, 2014, 2015, 2016, 2017 елларда Әлмәт муниципаль районы территориясендә зыян күрүчеләр һәм һәлак булучылар белән юл-транспорт һәлакәте статистикасы

Табл. № 2

| Еллар | Зыян күрүчеләр һәм һәлак булучылар белән юл-транспорт һәлакәте саны | Һәлак булучылар саны | Зыян күрүчеләр саны |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 2012 | 297 | 39 | 405 |
| 2013 | 247 | 37 | 402 |
| 2014 | 304 | 33 | 427 |
| 2015 | 239 | 42 | 326 |
| 2016 | 196 | 26 | 259 |
| 2017 | 176 | 23 | 207 |

2012, 2013, 2014, 2015, 2016, 2017 еллар эчендә Федераль әһәмияттәге «Казан-Оренбург " автомобиль юлында аварияләргә чагыштырма анализ

Табл. № 3

| Еллар | Һәлак булучылар белән юл-транспорт һәлакәте саны | Һәлак булучылар саны |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 2012 | 11 | 12 |
| 2013 | 12 | 14 |
| 2014 | 2 | 3 |
| 2015 | 13 | 17 |
| 2016 | 8 | 8 |
| 2017 | 6 | 7 |

2012, 2013, 2014, 2015, 2016, 2017 еллар чорында төбәк әһәмиятендәге автомобиль юллары аварияләренә чагыштырма анализ

Табл. № 4

| Еллар | Һәлак булучылар белән юл-транспорт һәлакәте | Һәлак булучылар саны |
|---|---|---|

| | саны | |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 2012 | 16 | 20 |
| 1 | 2 | 3 |
| 2013 | 12 | 15 |
| 2014 | 15 | 18 |
| 2015 | 13 | 19 |
| 2016 | 11 | 14 |
| 2017 | 7 | 7 |

2012 2013, 2014, 2015, 2016, 2017 елларда җирле әһәмияттәге юлларда булган аварияләргә чагыштырма анализ

Табл. № 5

| Еллар | Һәлак булучылар белән юл-транспорт һәлакәте саны | Һәлак булучылар саны |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 2012 | 7 | 7 |
| 2013 | 8 | 8 |
| 2014 | 8 | 8 |
| 2015 | 5 | 6 |
| 2016 | 3 | 3 |
| 2017 | 3 | 5 |

Юл-транспорт һәлакәтләрен профилактикалау һәм кисәтү буенча күрелә торган чаралар юлларда аварияләр үсешен тоткарлап торуда ярдәм итми.

Җәмгыять үсешенең хәзерге этабында юл-транспорт һәлакәтләрен кисәтү чаралары социаль-икътисадый шартларның үзгәрүе белән каршылыкларга килә, иң җитди каршылыклар:

- юлларда автотранспорт санының артуы автомобиль юллары һәм транспорт чишелешләре инфраструктурасы үсешен шактый узып китә;

- автотранспорт предприятиеләренең күпчелеге шәһәр читендә урнашкан. Димәк, Әлмәт шәһәренең урам-юл челтәре буенча хәрәкәт итүче йөк транспортының өлеше шактый зур;

- халыкның юл хәрәкәте шартлары үзгәрүчән юлларда үз-үзеңне тоту культурасы дәрәҗәсенә туры килмәве;

- юл хәлен бәяләүдә хата җибәрүче машина йөртүчеләр әзерләүнең түбән сыйфаты, канәгатьләнмәслек дисциплина, транспорт чаралары белән идарә иткәндә машина йөртүчеләрнең игътибарсызлыгы һәм салкын карашы;

- юл хәрәкәте иминлеге буенча чараларны техник яктан тәэмин итү җитешсезлекләре, беренче чиратта, юл хуҗалыкларының техник дәрәҗәсенә туры килмәү, юл-транспорт һәлакәтләрен вакытында

ачыклауга һәм зыян күрүчеләргә беренче ярдәм күрсәтүгә китерә торган элемтә системаларындагы артта калу.

Һәлакәтлелекнең авыр хәле һәм алга таба вәзгыятьнең начараюына тенденцияләр булу күп очракта түбәндәге сәбәпләр белән аңлатыла:

- халыкның даими үсә торган мобильлеге;

-җәмәгать транспортында пассажирлар йөртүне киметү һәм шәхси транспорт белән пассажирлар йөртүне арттыру;

-автомобильләр саны арту һәм урам-юл челтәре озынлыгы арасында заманча транспорт агымнарына исәпләнмәгән диспропорция.

Мондый хәлләрнең нәтиҗәсе булып юл хәрәкәте шартларының начараюы, экологик хәлне бозу, бөкеләр, ягулык чыгымын арттыру, шулай ук юл-транспорт һәлакәтләре санының артуы тора.

Хәзерге вакытта юл-транспорт һәлакәтләренең 70 проценттан артыгы торак пунктларда була. Торак пунктларда юл-транспорт һәлакәтләре нәтиҗәсендә зыян күргән кешеләр саны арту юл-транспорт һәлакәтләре саны арту темпларыннан алда бара.

Хәзерге заман юл-транспорт травматизмы үзенчәлекләрен анализлау күрсәткәнчә, юл-транспорт һәлакәтләре саны акрынлап арта бара, алар нәтиҗәсендә зыян күрүчеләр аерым дәрәҗәдәге җәрәхәтләр ала. Мондый юл-транспорт һәлакәтләре нәтиҗәсендә зыян күргән затларга медицина ярдәме күрсәтү эшен нәтиҗәле оештырмау-аларның үлеменең төп сәбәпләреннән берсе.

Соңгы елларда автопарк санының тиз артуы һәм юл хәрәкәтенә яңа машина йөртүчеләрне һәм ташучыларны күпләп кертү юл хәрәкәте шартларын катлауландыруга китерде: Әлмәт муниципаль районы территориясендә урнашкан федераль һәм төбәк әһәмиятендәге юлларда да шәһәр урамнарындагы кебек үк транспорт агымнарының тыгызлыгы артты, шәһәр урамнарында да, федераль һәм төбәк әһәмиятендәге юлларда да хәрәкәт интенсивлыгы артты.

Гомумән алганда, урам-юл челтәренең алыштыргысыз геометрик параметрлары булганда транспорт саны арту аларның үткәрүчәнлек сәләте сизелерлек кимүгә китергән.

Мондый хәл юл-транспорт һәлакәтләренең барлык күрсәткечләрен даими киметү өчен тотрыклы шартлар тудырмый. Бу һәм башка каршылыклар юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү буенча муниципаль идарә системасын ничек камилләштерергә комплекслы проблема рәвешендә килеп баса.

## 2. ПРОГРАММАНЫҢ ТӨП МАКСАТЛАРЫ ҺӘМ БУРЫЧЛАРЫ

Программаның максаты-гражданнарның гомерен һәм сәламәтлеген саклауны тәэмин итү, аларның законлы хокукларының Әлмәт муниципаль районы юлларында имин хәрәкәт итү шартларына гарантияләрен арттыру.

Программаның максатларына ирешү шартлары булып түбәндәге бурычларны хәл итү тора:

- юл хәрәкәтендә катнашучыларның куркынычсызлыгын кисәтү системасын камилләштерү;

- балаларда юлларда куркынычсызлык күнекмәләре формалаштыру;

- транспорт чаралары һәм җәяүлеләр хәрәкәтен оештыру системасын камилләштерү, юл шартларын яхшырту;

- юл-транспорт һәлакәтләрендә зыян күрүчеләргә ярдәм күрсәтү системасын үстерү;

- юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү өлкәсендә эшчәнлекне норматив-хокукый, оештыру һәм методик яктан тәэмин итүне камилләштерү.

Әлеге бурычларга ирешү Әлмәт муниципаль районы территориясендә авариялелек күрсәткечләрен киметергә һәм, димәк, проблеманың социаль үтемлелеген киметергә мөмкинлек бирәчәк.

Программаның максатларына ирешүне бәяләү түбәндәге максатчан индикаторларны һәм программаның күрсәткечләрен файдаланып гамәлгә ашырыла:

- юл-транспорт һәлакәтләрендә һәлак булучылар саны;

- юл-транспорт һәлакәтләрендә һәлак булган балалар саны;

- социаль куркыныч (юл-транспорт һәлакәтләрендә һәлак булучылар саны 100 мең кешегә);

- транспорт куркынычы (юл-транспорт һәлакәтләрендә һәлак булучылар саны, 10 мең транспорт чарасына).

Программаның максатчан индикаторларының һәм күрсәткечләренең аны гамәлгә ашыру еллары буенча әһәмияте программага № 1 кушымтасында күрсәтелгән.

Программаны тормышка ашыру бер ел дәвамында планлаштырыла.

## 3. ПРОГРАММА ЧАРАЛАРЫ

Программа чараларын федераль бюджет, муниципаль берәмлек бюджеты, Татарстан Республикасы бюджеты һәм бюджеттан тыш чыганаклар хисабына финанслау планлаштырыла.

Юл-транспорт һәлакәтләре нәтиҗәсендә һәлак булучылар саны һәм юл-транспорт һәлакәтләре китереп чыгарган фактлар буенча структур анализ нигезендә Әлмәт муниципаль районында юл-транспорт һәлакәтенә бәйле хәлне яхшыртырга сәләтле программаның түбәндәге юнәлешләре билгеләнде:

- юл хәрәкәте өлкәсендә хокук бозуларга тискәре мөнәсәбәт формалаштыру максатында халыкка пропаганда йогынтысы системасын булдыру;

-балалар арасында юл-транспорт травматизмын профилактикалауны арттыру;

-транспорт һәм җәяүлеләр хәрәкәтен оештыру, шул исәптән юл-транспорт һәлакәтләре концентрациясе урыннарын бетерү буенча эшләр күләме шактый артты;

-юл чыгымнарын булдырмау, урам-юл челтәре участокларында тиз йөрешле хәрәкәт режимын оптимальләштерү, юл хәрәкәтен оештыруның заманча инженерлык схемаларын, заманча техник чараларны (светофорлар, юл билгеләре, термопластик материаллардан юл тамгаларын һ.б.)

- җәяүлеләр кичү урыннарын норматив таләпләргә этаплап китерү;

- юлларның аеруча куркыныч участокларында юл киртәләре урнаштыру;

- урам-юл челтәренең аеруча куркыныч участокларында урамнарны яктырту челтәрләрен төзү;

- светофор объектларын модернизацияләү (реконструкцияләү).

Юл хәрәкәтендә катнашучыларның куркыныч тәртибен кисәтү системасын үстерү юнәлешендә эшчәнлек куркынычсыз юл хәрәкәте буенча белемнәр һәм күнекмәләр формалаштыруны, юл-транспорт һәлакәтләренә китерә торган потенциаль хәлләр турында мәгълүмат бирүне, юлларда үз-үзеңне тоту әдәбен үстерүне, җәмгыятьтә юлда социаль-хокукый нормаларга һәм хокукый нигилизмны кимсетмәү фактларына түзеп тормауны, транспорт чараларын йөртүчеләрне әзерләү системасын камилләштерүне һәм үстерүне күздә тота, юл хәрәкәтендә катнашучылар тарафыннан юл хәрәкәте кагыйдәләре таләпләрен, шул исәптән автомат режимда эшләүче юл хәрәкәте өлкәсендә административ хокук бозуларны теркәү системасын кулланып, фото һәм кино төшерү, видеоязма функциясенә ия махсус техник чаралар яисә фото - һәм кино төшерү, видеоязма чаралары белән үтәүне тәэмин итү.

Юл хәрәкәтендә катнашучыларның куркыныч тәртипләрен кисәтү системасын үстерүгә юнәлдерелгән программа чаралары программага 2 нче кушымтада китерелгән.

Балаларның юл хәрәкәтендә имин катнашуларын тәэмин итү юнәлешендәге эшчәнлек кысаларында балалар һәм яшүсмерләрне юл хәрәкәте кагыйдәләренә өйрәтүне, балаларда юлларда куркынычсызлык кагыйдәләре булдыру, балаларның юл хәрәкәтендә катнашу дисциплинасын ныгыту һәм контрольдә тотуны һәм балаларның юл хәрәкәтендә имин катнашуы шартларын булдыруны күздә тота.

Юл хәрәкәтендә балаларның иминлеген тәэмин итүгә юнәлдерелгән программа чаралары 3 нче кушымтада китерелгән.

Транспорт чаралары һәм җәяүлеләр хәрәкәтен оештыру системасын үстерү, юл шартларының иминлеген арттыру юнәлешендә эшчәнлек җәяүлеләрнең юл хәрәкәтендә имин катнашуларын тәэмин итү, юл хәрәкәтендә куркыныч участоклар барлыкка килүне бетерү һәм профилактикалау, юл хәрәкәте иминлеген һәм нәтиҗәле трафик тәэмин

итү максатларында транспорт планлаштыруын оештыру, интеллектуаль транспорт системасын үстерү, юлларның һәм юл инфраструктурасының пассив һәм аварияләрдән соңгы иминлеген тәэмин итү күздә тотыла.

Транспорт чаралары һәм җәяүлеләр хәрәкәтен оештыру системасын үстерүгә, юл шартларының куркынычсызлыгын арттыруга юнәлдерелгән программа чаралары программага 4 нче кушымтада китерелгән.

Юл-транспорт һәлакәтләрендә зыян күрүчеләргә ярдәм күрсәтү системасын үстерү юнәлешендә эшчәнлек юл-транспорт һәлакәтләрендә зыян күрүчеләргә медицина ярдәме күрсәтүнең оперативлыгын һәм сыйфатын тәэмин итү, медицина учреждениеләренең территориаль мөмкинлеген тәэмин итү, юл-транспорт һәлакәтләрендә зыян күрүчеләргә ярдәм күрсәтүдә катнашучы хезмәтләрне координацияләү дәрәҗәсен арттыру, юл-транспорт һәлакәтләрендә зыян күрүчеләргә беренче ярдәм күрсәтү өлкәсенә яңа технологияләр кертү күздә тотыла.

Юл-транспорт һәлакәтләрендә зыян күрүчеләргә ярдәм күрсәтү системасын үстерүгә юнәлдерелгән программа чаралары программага 5 нче кушымтада китерелгән.

Юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү өлкәсендә эшчәнлекне норматив-хокукый, оештыру һәм методик тәэмин итүне камилләштерү юнәлеше кысаларында эшчәнлек законнардагы җитешсезлекләр бетерүне, дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыруның гамәли ысулларын эшләүне һәм кертүне күздә тота.

Юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү өлкәсендә эшчәнлекне норматив-хокукый, оештыру һәм методик тәэмин итүне камилләштерүгә юнәлдерелгән программа чаралары программага 6 нчы кушымтада китерелгән.

## 4. ПРОГРАММАНЫ РЕСУРСЛАР БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ

2019 елга Программаны финанслауның гомуми күләме 22,388 млн сум тәшкил итә, шул исәптән:
- Федераль бюджет акчасыннан 5,459 млн сум;
- Татарстан Республикасы бюджеты акчаларыннан 0,470 млн сум;
- Муниципаль берәмлек бюджеты акчасыннан 4,309 млн сум;
- Бюджеттан тыш чыганаклардан 12,150 млн сум.

Юнәлешләр буенча программаны финанслау күләме программага 7 нче кушымтада китерелгән.

Барлык чыганаклардан программаны финанслау күләме программаның 8 нче кушымтасында китерелгән.

Программа заказчылары арасында акчаларны бүлү программага 9 нчы кушымтада китерелгән.

Муниципаль берәмлек бюджеты хисабына программаны финанслау күләме фаразланган характерда һәм реаль мөмкинлекләрдән чыгып төгәлләштерелергә тиеш.

## 5. ПРОГРАММАНЫ ГАМӘЛГӘ АШЫРУ МЕХАНИЗМЫ

Программа чараларын гамәлдәге законнар нигезендә район башкарма комитеты арасында төзелә торган муниципаль ихтыяҗлар өчен продукция сатып алу һәм китерүгә муниципаль контрактлар (килешүләр) нигезендә гамәлгә ашыру күздә тотыла.

Программаны тормышка ашыру эшчәнлеген координацияләүне район башкарма комитеты башкара. Программаны тормышка ашыру белән нәтиҗәле идарә итү һәм формалаштыру мәсьәләләрен хәл итү идарә итү формаларын һәм методларын нигезле сайлап алу юлы белән тормышка ашырылачак.

### Программаны гамәлгә ашыру белән идарә итүнең оештыру-хокукый аспектлары

Программаны тормышка ашыру белән идарә итүне район башкарма комитеты башкара.

Программаның җитәкчесе-район башкарма комитеты җитәкчесе, юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү буенча комиссия рәисе урынбасары.

Программа заказчыларының үзара хезмәттәшлеген Әлмәт муниципаль районы башкарма комитеты каршындагы юл хәрәкәте куркынычсызлыгы комиссиясе тәэмин итә.

Әлеге программаны тормышка ашыру белән агымдагы идарә итүне Әлмәт муниципаль районы башкарма комитеты каршындагы юл хәрәкәте куркынычсызлыгы комиссиясе рәисе башкара.

Юл хәрәкәте иминлеге комиссиясе түбәндәге төп функцияләрне гамәлгә ашыра:

- программа чараларын гамәлгә ашыру турында статистик һәм аналитик мәгълүмат җыю һәм системалаштыру;
- программа чараларын гамәлгә ашыру нәтиҗәләрен мониторинглау, әлеге чараларны гамәлгә ашыру турында аналитик мәгълүмат формалаштыру һәм программаны гамәлгә ашыру турында хисап әзерләү;
- программа чараларының нәтиҗәлелеге күрсәткечләрен, аларның программа индикаторларына һәм күрсәткечләренә туры килүен бәйсез бәяләүне оештыру;
- программаны гамәлгә ашыруның барышы һәм нәтиҗәләре турында җәмәгатьчелеккә мәгълүмат җиткерү буенча эшчәнлекне гамәлгә ашыру;
-башка функцияләр.

## 6. ПРОГРАММАНЫҢ СОЦИАЛЬ-ИКЪТИСАДЫЙ,БЮДЖЕТ ҺӘМ ЭКОЛОГИК НӘТИҖӘЛЕЛЕГЕН БӘЯЛӘҮ

Программаны гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеге юл хәрәкәтендә катнашучыларның гомерен саклап калудан, юл-транспорт һәлакәтләреннән һәм аларның нәтиҗәләреннән социаль икътисадый һәм демографик зыяннарны булдырмый калудан гыйбарәт.

2019 елда инерцион сценарийлар белән чагыштырганда, бер ел эчендә һәлак булган затларны 15 кешегә кыскарту көтелә: 45-30=15 (программага 11 нче кушымта).

Программаның бюджет нәтиҗәлелеге анық чараларын гамәлгә ашыруның федераль бюджет һәм муниципаль берәмлек бюджеты керемнәренә һәм чыгымнарына йогынтысын чагылдыра.

Программаны гамәлгә ашыруның социаль-икътисадый нәтиҗәлелеге икътисадый һәм финанс күрсәткечләренең яхшыруын характерлый торган сыйфатлы һәм санлы параметрлар, шулай ук демографик вәзгыятьне яхшыртуга йогынты ясый торган күрсәткечләр (үлүчеләр саны, шул исәптән балалар үлеме саны киму) һәм халыкның үлем-китеменнән социаль-икътисадый зыянның программа чараларын гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә кимүгә китерә.

Программаның экологик нәтиҗәлелеге программа чараларын үтәү белән тәэмин ителә, аларны гамәлгә ашыру нәтиҗәсе булып куркыныч йөк ташучы транспорт чаралары катнашында юл-транспорт һәлакәтләре санын киметү тора.

Программа чараларын гамәлгә ашыруның уңай социаль-икътисадый һәм экологик нәтиҗәләре юл хәрәкәтен оештыруның яңа ысулларын гамәлгә кертүгә бәйле булачак. Оптималь маршрутларны куллану һәм юлда булу вакыты аз булу хисабына углерод окисе һәм азот окислары чыгару кыскартылачак, бу исә экологиягә уңай йогынты ясаячак.

Программа «2013-2020 елларда юл хәрәкәте иминлеген арттыру» федераль максатчан программасы нигезендә эшләнгән, анда социаль-икътисадый һәм бюджет нәтиҗәлелеген исәпләү юл-транспорт һәлакәтләрендә һәлак булган затлар саны, бюджет акчаларын тоту, инфляция индексы, дисконтлау коэффициенты һәм башка күрсәткечләр нигезендә гамәлгә ашырылган. Программаның социаль-икътисадый һәм бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре өчен инфляция индексы һәм дисконтлау коэффициенты кебек параметрларны үзгәртү актуаль.

Программаны гамәлгә ашыруның социаль-икътисадый нәтиҗәсе юл-транспорт һәлакәтләреннән һәм аларның нәтиҗәләрен программа чараларын гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә, аны гамәлгә ашыру чыгымнарын тотып калынган өчен киметү булып тора. Китерелгән социаль-икътисадый нәтиҗә бер ел эчендә дисконтлау коэффициентына гомуми агымдагы нәтиҗәнең мөнәсәбәте буларак исәпләнә.

Программаның нәтиҗәлелеге исәп-хисапларында тиешле еллар бәяләре кулланыла, шул ук вакытта дисконтлау нормативы программаны гамәлгә ашыруның бөтен чоры дәвамында үзгәрешсез кала һәм 1,11 тәшкил итә, инфляция дәрәҗәсе Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгы мәгълүматлары нигезендә билгеләнә һәм Программаны гамәлгә ашыруның киләсе һәр елы индексацияләнә, ә зыян күләме нормативы юл-транспорт һәлакәтләреннән социаль-икътисадый зыяннарны бәяләү һәм исәпләү методикасы нигезендә билгеләнә.

Программа чараларын тормышка ашырудан көтелгән социаль-икътисади нәтиҗә 64,994 млн сум тәшкил итәчәк.

Программаның социаль-икътисадый нәтиҗәлелеген исәпләү программага 10 нчы кушымтада китерелгән.

Бюджет нәтиҗәлелеген исәпләгәндә, чараларны гамәлгә ашыру чыгымнарын исәпкә алып, бюджет керемнәрен формалаштыруга программа чараларының өлеше бәяләнә. Көтелгән бюджет нәтиҗәсе 48,154 млн. сум тәшкил итәчәк.

Программаның бюджет нәтиҗәлелеген исәпләү программага 11 нче кушымтада китерелгән.

Район башкарма комитеты
җитәкчесенең төзелеш буенча
урынбасары А.А. Мөхәммәтҗанов

“Әлмәт муниципаль районында
2019 елга юл хәрәкәте иминлеген арттыру ”униципаль программасына
1 нче кушымта

## Программа индикаторлары һәм күрсәткечләре

| №№ | Исеме | үлчәү берәм леге | 2012 ел | шул исәптән еллар буенча | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2013 | 2014 | 2015 | 2016 | 2017 | 2018 | 2019 | 2020 |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
| 1. | 2012 ел белән чагыштырганда юл-транспорт һәлакәтләрендә һәлак булучылар саны | чел. | 39 | 38 | 38 | 37 | 37 | 34 | 32 | 30 | 28 |
| | 2012 елга үзгәрешләр | % | - | -1,47 | -2,64 | -4,2 | -5,33 | -12,86 | -18,58 | -24,01 | -28,82 |
| | 2012 елга үзгәрешләр | чел. | - | 1 | 1 | 2 | 2 | 5 | 7 | 9 | 11 |
| 2. | 2012 ел белән чагыштырганда юл-транспорт һәлакәтләрендә һәлак булган балалар саны | чел. | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 |
| | 2012 елга үзгәрешләр | % | - | -0,53 | -4,15 | -7,23 | -11,7 | -15,74 | -21,38 | -28,19 | -28,4 |
| | 2012 елга үзгәрешләр | чел. | - | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 |
| 3. | Социаль куркыныч (юл-транспорт һәлакәтләрендә һәлак булучылар саны 100 мең кешегә | чел. | 20 | 19,7 | 19,3 | 18,9 | 18,5 | 17,9 | 15,8 | 14,5 | 13,9 |
| | 2012 елга үзгәрешләр | % | - | -1,5 | -3,5 | -5,5 | -7,5 | -10,5 | -21 | -27,5 | -30,5 |
| | 2012 елга үзгәрешләр | чел. | - | -0,3 | -0,7 | -1,1 | -1,5 | -2,1 | -4,2 | -5,5 | -6,1 |
| 4. | Транспорт куркынычы (юл-транспорт һәлакәтләрендә һәлак булучылар саны 10 мең транспорт чарасына) | чел. | 6 | 5,991 | 5,981 | 5,783 | 5,606 | 5,243 | 4,319 | 3,915 | 3,836 |
| | 2012 елга үзгәрешләр | % | - | -0,16 | -0,33 | -3,61 | -6,56 | -12,62 | -28,03 | -34,75 | -36,07 |
| | 2012 елга үзгәрешләр | чел. | чел. | 0,009 | 0,019 | 0,217 | 0,394 | 0,757 | 1,681 | 2,085 | 2,164 |

“Әлмәт муниципаль районында
2019 елга юл хәрәкәте иминлеген
арттыру ” муниципаль программасына
2 нче кушымта

Юл хәрәкәтендә катнашучыларның куркынычсызлык тәртипләрен кисәтү системасын үстерүгә юнәлдерелгән чаралар

| №№ | Чаралар исеме | Үтәлү вакыты | Финанслау күләме | шушында | | | Үтәү өчен җаваплы | Көтелгән нәтиҗә |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | МБ бюджеты хисабына | Россия Федерациясе бюджеты акчалары хисабына | бюджеттан тыш чыганаклар хисабына | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
| | Башка ихтыяҗлар | | | | | | | |
| | Финанс түләүләресез үткәрелә торган чаралар | | | | | | | |
| 1. | Коммуникацияләрнең нәтиҗәле каналларын кулланучы мәгълүмати-пропаганда кампанияләрен үткәрү, аңлылык, җаваплылык һәм дәрәҗәләрне күтәрү максаты белән | 2019 ел | - | - | - | - | ЮХИДИ бүлеге (килешү буенча) | машина йөртүчеләрдә һәм пассажирларда норматив кыйммәтләргә мотивация формалаштыру |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | юл хәрәкәтендә катнашучыларның үзаңы һәм юл-транспорт һәлакәтләре санына һәм аларның нәтиҗәләре авырлыгына йогынты ясый торган куркыныч факторларны профилактикалау (җирле телеканалда) | | | | | | | юлда үз-үзеңне куркынычсыз тоту әдәбен, хокукый аңны арттыруга юнәлдерелгән |
| 2. | Массакүләм мәгълүмат чараларында юл хәрәкәте иминлеге буенча проблемалы мәсьәләләрне системалы рәвештә яктырту өчен махсус тематик рубрикалар оештыру, махсус басма продукция чыгару | 2019 ел | - | - | - | - | район Советы Аппаратының җәмәгатьчелек һәм ММЧ белән үзара эшчәнлек бүлеге (килешү буенча) | юл хәрәкәтендә катнашучыларның хокукый аңын арттыру, юлларда куркынычсызлык кагыйдәләрен һәм җаваплылыгын арттыру |

“Әлмәт муниципаль районында
2019 елга юл  хәрәкәте иминлеген
арттыру ”муниципальпрограммасына
3 нче кушымта

Юл хәрәкәтендә балаларның иминлеген тәэмин итүгә юнәлдерелгән чаралар

| №№ п/п | Чаралар исеме | Үтәлү вакыты | Финанслау күләме | шушында | | | Үтәү өчен җаваплы | Көтелгән нәтиҗә |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | МБ бюджеты хисабына | Россия Федерациясе бюджеты акчалары хисабына | бюджеттан тыш чыганаклар хисабына | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
| | Башка ихтыяҗлар | | | | | | | |
| 1. | Мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре, мәгариф учреждениеләре, | 2019 ел | 0,150 | - | 0,150 | - | Әлмәт шәһәре “Юл хәрәкәте иминлеге” дәүләт бюджет учреждениесе (килешү буенча) | балалар юл-транспорт травматизмын кисәтү |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | балаларга өстәмә белем бирү системасының белем бирү учреждениеләре өчен фәнни-методик материаллар, программалар, уку әсбаплары нәшер итү (уку әсбапларының, программаларның пилот комплектлары белән тәэмин итү) | | | | | | | |
| 2. | Балалар юл - транспорт травматизмын кисәтү буенча шәһәр чаралары үткәрү:"Светофорик», «Куркынычсыз тәгәрмәч», асфальтта рәсемнәр конкурсы, «Өлкән җәяүлеләр балалар күзлегеннән", яшүсмерләр клублары арасында бәйге, «Юл хәрәкәте кагыйдәләрен белсәң - ЮХИДИ белән проблемаң юк», картинг буенча шәхси - команда беренчелеге һ. б. | 2019 ел | 0,250 | - | 0,250 | - | Әлмәт шәһәре “Юл хәрәкәте иминлеге” дәүләт бюджет учреждениесе (килешү буенча) | Балаларда, өлкәннәрдә юл хәрәкәтендә катнашучыларда юл йөрү куркынычсызлык күнекмәләре формлаштыру |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 3. | Гомуми белем бирү мәктәпләре һәм мәктәпкәчә балалар учреждениеләре укытучылар составының квалификациясен күтәрү | 2019 ел | 0,070 | - | 0,070 | - | Әлмәт шәһәре “Юл хәрәкәте иминлеге” дәүләт бюджет учреждениесе (килешү буенча) | мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә, аеруча башлангыч сыйныфларда, юл хәрәкәте кагыйдәләрен мәҗбүри өйрәнүнең тулы бер системасын булдыру |
| 4. | Мәктәпкәчә яшьтәге балалар һәм белем бирү оешмалары укучылары арасында яктылык кайтаручы җайланмалар әзерләү һәм тарату | 2019 ел | - | - | - | - | Әлмәт муниципаль районы мәгариф идарәсе (килешү буенча) | тәүлекнең караңгы вакытында балалар юлда йөрү ихтималын киметү |
| | Барысы: | | 0,470 | - | 0,470 | - | | |

“Әлмәт муниципаль районында
2019 елга юл хәрәкәте иминлеген
арттыру ” муниципаль программасына
4 нче кушымта

Транспорт чаралары һәм җәяүлеләр хәрәкәтен оештыру системасын үстерүгә,
юл хәрәкәте иминлеге шартларын яхшыртуга юнәлдерелгән чаралар

| №№ | Чаралар исеме | Үтәлү вакыты | Финанслау күләме | шушында | | | Үтәү өчен җаваплы | Көтелгән нәтиҗә |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | МБ бюджеты хисабына | Россия Федерациясе бюджеты акчалары хисабына | бюджеттан тыш чыганаклар хисабына | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
| | Капитал кертү | | | | | | | |
| 1. | Шәһәрләрне һәм торак пунктларны җәяүлеләр өчен коймалар белән тәэмин итү, шул исәптән җәяүлеләр кичү урыннары зонасында | 2019 ел | 6,300 | - | 3,150 | 3,150 | район башкарма комитеты | җәяүлеләргә юл йөрү өлешенә чыгу мөмкинлеге бирмәү |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 2. | Сакланыла торган җәяүлеләр кичү юлларын,шул исәптән мәгариф учреждениеләренә якын-тирә яктыртуны, ясалма юл тигезсезлекләрен, Т.7. светофорлары, эчке яктырту билгеләре, юл тамгалары белән, шул исәптән юл хәрәкәте иминлеген арттыруның штуч формаларын һәм төсле юл катламнарын һәм башка элементларын кулланып модернизацияләү | 2019 ел | 2,374 | 1,187 | 1,187 | - | район башкарма комитеты | җәяүлеләр кичү урыннарында юл хәрәкәте иминлеген арттыру |
| 3. | Светофор объектларын төзү, модернизацияләү (юл контроллерларын алмаштыру, тавыш белән тәэмин итү, вакытны киредән санаучы табло урнаштыру | 2019 ел | 2,244 | 1,122 | 1,122 | - | район башкарма комитеты | урам-юл челтәренең үткәрү сәләтен арттыру |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 4. | Урам-юл челтәренең куркыныч участокларында урамнарны яктырту челтәрләре төзү | 2019 ел | 5,000 | - | - | 5,000 | район башкарма комитеты | тәүлекнең караңгы вакытында юл-транспорт һәлакәтләре киму |
| | Башка ихтыяҗлар | | | | | | | |
| | Юл хәрәкәте куркынычсызлыгын арттыруга юнәлдерелгән чаралар, әмма федераль максатчан программа буенча №№ 2-7 кушымталарында күрсәтелмәгән | | | | | | | |
| 5. | Урам - юл челтәрендә юл билгеләре төшерү (155 км) | 2019 ел | 6,000 | 2,000 | - | 4,000 | район башкарма комитеты | |
| | Барысы: | | 21,918 | 4,309 | 5,459 | 12,150 | | |

“Әлмәт муниципаль районында
2019 елга юл хәрәкәте иминлеген
арттыру ” муниципаль программасына
5 нче кушымта

Юл-транспорт һәлакәтләрендә зыян күрүчеләргә ярдәм күрсәтү системасын үстерүгә юнәлдерелгән чаралар

| №№ | Чаралар исеме | Үтәлү вакыты | Финанслау күләме | шушында | | | Үтәү өчен җаваплы | Көтелгән нәтиҗә |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | МБ бюджеты хисабына | Россия Федерациясе бюджеты акчалары хисабына | бюджеттан тыш чыганаклар хисабына | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
| | Башка ихтыяҗлар | | | | | | | |
| | Финанссыз үткәрелә торган чаралар | | | | | | | |
| 1. | Гадәттән тыш хезмәтләрнең үзара хезмәттәшлеге һәм авария-коткару эшләрен үткәрү мәсьәләләрен гамәли эшкәртү | 2019 | - | - | - | - | ТР ӘМР буенча МЧС идарәсе (килешү буенча) | юл-транспорт һәлакәтләре нәтиҗәләрен бетерүдә ведомствоара хезмәттәшлекне камилләштерү |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | юл-транспорт һәлакәтләре | | | | | | | |
| 2. | ТР Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының ӘМР буенча идарәсенең Юл хәрәкәте иминлеге өлкәсендә коммуникатив чараларда һәм юл-транспорт һәлакәтләрендә зыян күрүчеләргә ярдәм итүдә катнашуы | 2019 | - | - | - | - | ТР ӘМР буенча МЧС идарәсе (килешү буенча) | юл-транспорт һәлакәтләре нәтиҗәсендә зыян күргән балаларга медицина ярдәме күрсәтүнең яңа технологияләрен һәм ысулларын эшләү |

“Әлмәт муниципаль районында
2019 елга юлхәрәкәте иминлеген
арттыру ” муниципаль программасына
6 нчы кушымта

## Юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү өлкәсендә эшчәнлекне норматив-хокукый, оештыру һәм методик тәэмин итүне камилләштерүгә юнәлдерелгән чаралар

| №№ | Чаралар исеме | Үтәлү вакыты | Финанслау күләме | шушында | | | Үтәү өчен җаваплы | Көтелгән нәтиҗә |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | МБ бюджеты хисабына | Россия Федерациясе бюджеты акчалары хисабына | бюджеттан тыш чыганаклар хисабына | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
| | Фәнни-тикшеренү һәм тәҗрибә-конструкторлык эшләре | | | | | | | |
| | Финансларсыз үткәрелә торган чаралар | | | | | | | |
| 1. | Юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итүнең өстенлекле проектларына бюджеттан тыш финанс чараларын җәлеп итү, дәүләт-шәхси партнерлыкны үстерү буенча нәтиҗәле механизмнарны эшләү | 2019 | - | - | - | - | район башкарма комитеты | юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү өлкәсендә дәүләтнеке булмаган оешмаларның ролен арттыру |

“Әлмәт муниципаль районында
2019 елга юл хәрәкәте иминлеген
тәэмин итү” муниципаль
программасына
7 нче кушымта

Акчаларны тоту юнәлешләре буенча федераль бюджет, Татарстан Республикасы бюджеты, муниципаль берәмлек бюджеты һәм бюджеттан тыш чыганаклар хисабына программаны финанслау күләме

| Күрсәткечләр | 2019 | Федераль бюджет | | | Муниципаль берәмлек бюджеты | | | Татарстан Республикасы бюджеты акчалары | | | Бюджеттан тыш чыганаклар | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | НИО КР | кап. кертем | башка ихтыяҗлар | НИО КР | кап. кертем | башка ихтыяҗлар | НИО КР | кап. кертем | башка ихтыяҗлар | НИО КР | кап. кертем | башка ихтыяҗлар |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 |
| Юл хәрәкәтендә катнашучыларның куркыныч тәртибен кисәтү системасын үстерү | - | - | - | - | - | - | - | - | - | - | - | - | - |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Балаларның юл хәрәкәтендә имин катнашуларын тәэмин итү | 0,470 | - | - | - | - | - | - | - | - | 0,470 | - | - | - |
| Транспорт чараларының техник торышы дәрәҗәсен күтәрү, аларның актив һәм пассив куркынычсыз лыгы дәрәҗәсен күтәрү | - | - | - | - | - | - | - | - | - | - | - | - | - |
| Транспорт чаралары һәм җәяүлеләр хәрәкәтен оештыру системасын үстерү, юл шартларын яхшырту | 21,918 | - | 5,459 | - | - | 2,309 | 2,000 | - | - | - | - | 8,150 | 4,000 |
| Юл-транспорт һәлакәтләрендә зыян күрүчеләргә ярдәм күрсәтү системасын үстерү | - | - | - | - | - | - | - | - | - | - | - | - | - |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Юл-транспорт һәлакәтләрендә зыян күрүчеләргә ярдәм күрсәтү системасын үстерү | - | - | - | - | - | - | - | - | - | - | - | - | |
| Барысы: | 22,388 | - | 5,459 | - | - | 2,309 | 2,000 | - | - | 0,470 | - | 8,150 | 4,000 |

“Әлмәт муниципаль районында
2019 елга юл хәрәкәте иминлеген
арттыру ” муниципаль программасына
8 нче кушымта

2019 елга федераль бюджет, Татарстан Республикасы бюджеты, муниципаль берәмлек бюджеты һәм бюджеттан тыш чыганаклар хисабына программаны финанслау күләме

(млн сум, в 2018 ел бәяләре)

| Финанслау чыганагы | 2017 ел |
|---|---|
| 1 | 2 |
| Федераль бюджет – барлыгы, шулай ук: | 5,459 |
| капиталь кертем | 5,459 |
| башка ихтыяҗлар | - |
| Татарстан Республикасы бюджеты акчалары – барлыгы, шулай ук: | 0,470 |
| капиталь кертем | - |
| башка ихтыяҗлар | 0,470 |
| Муниципаль берәмлек бюджеты акчалары – барлыгы, шулай ук: | 4,309 |
| капиталь кертем | 2,309 |
| башка ихтыяҗлар | 2,000 |
| Бюджеттан тыш чыганаклар акчалары – барлыгы, шулай ук: | 12,150 |
| капиталь кертем | 8,150 |
| башка ихтыяҗлар | 4,000 |
| Барлыгы: барлык чыганаклардан программаны финанслау күләме | 22,388 |

“Әлмәт муниципаль районында
2019 елга юл хәрәкәте иминлеген
арттыру ” муниципаль программасына
9 нчы кушымта

Программаны финанслау күләмен программа заказчылары арасында бүлү

| программа заказчылары | 2019 ел | капиталь кертем | башка ихтыяҗлар |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| ЮХИДИ бүлеге | - | - | - |
| Юл хәрәкәтендә катнашучыларның куркыныч тәртибен кисәтү системасын үстерү | - | - | - |
| Балаларның юл хәрәкәтендә имин катнашуларын тәэмин итү | 0,470 | - | 0,470 |
| Транспорт чаралары һәм җәяүлеләр хәрәкәтен оештыру системасын үстерү, юл шартларын яхшырту | 21,918 | 15,918 | 6,000 |
| Юл-транспорт һәлакәтләрендә зыян күрүчеләргә ярдәм күрсәтү системасын үстерү | - | - | - |
| Юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү өлкәсендә эшчәнлекне норматив-хокукый, оештыру һәм методик яктан тәэмин итүне камилләштерү | - | - | - |
| Гомуми сумма: | 22,388 | 15,918 | 6,470 |

“Әлмәт муниципаль районында
2019 елга юл хәрәкәте иминлеген
арттыру ” муниципаль программасына
10 нчы кушымта

Программаның социаль-икътисадый нәтиҗәлелеген исәпләү

| №№ | Күрсәткечләр | 2012 ел (база) | 2019 ел |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Юл-транспорт һәлакәтләре нәтиҗәсендә һәлак булучылар саны (программа күрсәткече) мең кеше | | 30 |
| 2. | Юл-транспорт һәлакәтләре нәтиҗәсендә һәлак булучыларның саны (инерцион сценарий – программа-максатчан алым булмау шартларында вәзгыятьне үстерү), кеше | 39 | 45 |
| 3. | Инерцион сценарийлар белән чагыштырганда һәлак булучылар саны кимү, кеше | | 15 |
| 4. | Социаль-икътисадый зыянның кимүе, млн сум | | 85,92 |
| 5. | Программаны тормышка ашыру өчен чыгымнар, млн. сум | | 22,388 |
| 6. | Инфляция индексы | | 1,625 |
| 7. | Инфляцияне исәпкә алып чыгымнар, млн сум | | 13,777 |
| 8. | Социаль-икътисади нәтиҗә, млн сум | | 72,143 |
| 9. | Дисконтлау коэффициенты | | 1,11 |
| 10. | Китерелгән социаль-икътисади нәтиҗә, млн сум | | 64,994 |

“Әлмәт муниципаль районында
2019 елга юл хәрәкәте иминлеген
арттыру ” муниципаль программасына
11 нче кушымта

Программаның бюджет нәтиҗәлелеген исәпләү

| №№ | Күрсәткечләр | 2012 ел (база) | 2019 ел |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Юл-транспорт һәлакәтләре нәтиҗәсендә һәлак булучылар саны (программа күрсәткече) мең кеше | | 30 |
| 2. | Юл-транспорт һәлакәтләре нәтиҗәсендә һәлак булучыларның саны (инерцион сценарий – программа-максатчан алым булмау шартларында вәзгыятьне үстерү), кеше | 39 | 45 |
| 3. | Инерцион сценарийлар белән чагыштырганда һәлак булучылар саны кимү, кеше | | 15 |
| 4. | Социаль-икътисадый зыянның кимүе, млн сум | | 85,92 |
| 5. | Муниципаль бюджет керемнәренә өлеш, млн сум | | 63,58 |
| 6. | Программаны гамәлгә ашыру өчен муниципаль бюджеттан чыгымнар, млн сум | | 16,459 |
| 7. | Инфляция индексы | | 1,625 |
| 8. | Инфляцияне исәпкә алып, Программаны гамәлгә ашыру чыгымнары, муниципаль бюджеттан, млн. сум | | 10,129 |
| 9. | Бюджет нәтиҗәсе, млн сум | | 53,451 |
| 10. | Дисконтлау коэффициенты | | 1,11 |
| 11. | Китерелгән бюджет нәтиҗәсе, миллион сум | | 48,154 |